**СОВЕТ КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422626 с. Кирби,
ул. Горького, д.26а
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422626 Хәерби авылы,
Горкий урамы, 26а нчы йорт,
тел: 4-38-16

**2024 елның 26 марты** **110 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 12 декабрендәге 117 номерлы Хәерби авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (20.11.2023 елгы 78 номерлы карарлар редакциясендә)**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Хәерби авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 12 декабрендәге 117 номерлы Хәерби авыл җирлеге советы карарына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 12 статьяның 3 абзацына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 1 статьясындагы 7 пунктының 3_1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш.".

«3_1. Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына, шәһәр округының генераль планына үзгәрешләр кертелгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.".

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Хәерби**
**авыл җирлеге Советы рәисе Р.К.Зинәтуллин**